**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БЕГИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО МНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ул. Клубная д. 1, с. Бегишево, Заинский район, 423511**

**Клубная урамы, 1нче йорт, Бигеш авылы, Зәй районы, 423511**

Телефон, факс 3-82-25. Электронный адрес:Beg.zai@tatar.ru,сайт:http://zainsk.tatarstan.ru/rus/ begishevskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 2 31.01.2023

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 22 маендагы 13 номерлы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 339-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 22 маендагы 13 номерлы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган (Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 10 декабрендәге 25 номерлы, 2020 елның 17 июлендәге 15 номерлы, 2020 елның 16 октябрендәге 18 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу тәртибе турында

муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.1 пунктына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлекле 14 пунктны өстәргә:

«14) нотариаль таныкланган килешүләрнең эчтәлеген белдерә торган документларның дубликатларын бирергә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Р. Вәлиев**